| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 г. Казань № 642-143/тэ-2025

Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2024 ел, №663-109/тэ-2024 карары белән билгеләнгән тарифларга 2026 ел өчен үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 18.12.2025 ел, №34-ПР беркетмәсе нигезендә һәм 2026 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2026 елга җылылык энергиясенә тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «ТГК-16» АҖ) тарафыннан җылылык энергиясе югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә

(егәрлегенә) 2025-2029 елларга тарифлар билгеләү турында» 19.12.2024 ел, №663-109/тэ-2024 карары белән билгеләнгән тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертеп, кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пункты белән төзәтелгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2024 ел, № 663-109/тэ-2024
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 642-143/тэ-2025
карары редакциясендә)

# Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» АҖ тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2025-2029 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукциял әнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| 1 | «ТГК-16» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 1 027,19 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 1 223,18 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 1 223,18 | - | - | - | - | - |
| | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 1 345,45 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 1 272,04 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 1 322,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап | 1 322,92 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 30.06.2028 кадәр | | | | | | |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 1 375,84 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2029 башлап 30.06.2029 кадәр | 1 375,84 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2029 башлап 31.12.2029 кадәр | 1 430,87 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге